ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.05.2024 с.Старое Дрожжаное № 13

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 9 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 01 декабрендәге 48 номерлы (14.02.2019 № 11, 25.07.2023 № 32, 13.10.2023 № 43 номерлы редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенең 14 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле **14.8.1 пункт** өстәргә:

«14.8.1. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына I, II төркем инвалидлары, инвалид балалар һәм шундый балаларны озатып йөрүче затлар ия.

Чираттан тыш шәхси кабул ителү хокукына берьюлы берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килүе тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

**14.9 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.9. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхси кабул ителү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) кабул итүгә өч яше тулмаган балалар белән килгән гражданнар.

Беренче чиратта шәхси кабул ителү хокукына берьюлы берничә граждан ия булган очракта, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килүе тәртибендә гамәлгә ашырыла.»;

**14.10 пунктта** «14.9 п. күрсәтелгән» сүзләрен «14.8.1 һәм 14.9 пунктларда күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

**14.12 нче пунктны** үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы

М.Р. Гафаров